Документ подписан простой электронной подписью
Информация о владельце:
ФИО: Сыров Игорь Анатольевич
Должность: Директор
Дата подписания: 30.10.2023 15:09:24
Уникальный программный ключ:
b683afe664d7e9f64175886cf9626a198149ad36

СТЕРЛИТАМАКСКИЙ ФИЛИАЛ
ФЕДЕРАЛЬНОГО ГОСУДАРСТВЕННОГО БЮДЖЕТНОГО ОБРАЗОВАТЕЛЬНОГО
УЧРЕЖДЕНИЯ ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ
«УФИМСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ НАУКИ И ТЕХНОЛОГИЙ»

Факультет ***Башкирской и тюркской филологии***
Кафедра ***Татарской и чувашской филологии***

**Рабочая программа дисциплины (модуля)**

дисциплина ***Б1.В.17 История родного (татарского) языка***

часть, формируемая участниками образовательных отношений

Направление

***44.03.05*** ***Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)***
код наименование направления

Программа

***Родной (татарский, чувашский) язык и литература, Иностранный язык***

Форма обучения

**Очная**

Для поступивших на обучение в
**2023 г.**

Разработчик (составитель)
***кандидат филологических наук, доцент***
***Мукимова Н. А.***
ученая степень, должность, ФИО

Стерлитамак 2023

**1. Перечень планируемых результатов обучения по дисциплине, соотнесенных с установленными в образовательной программе индикаторами достижения компетенций** ........ 3

**2. Цели и место дисциплины (модуля) в структуре образовательной программы** ........ 3

**3. Объем дисциплины (модуля) в зачетных единицах с указанием количества академических или астрономических часов, выделенных на контактную работу обучающихся с преподавателем (по видам учебных занятий) и на самостоятельную работу обучающихся** ........ 4

**4. Содержание дисциплины (модуля), структурированное по темам (разделам) с указанием отведенного на них количества академических часов и видов учебных занятий** ........ 4

4.1. Разделы дисциплины и трудоемкость по видам учебных занятий (в академических часах) ........ 4

4.2. Содержание дисциплины, структурированное по разделам (темам) ........ 5

**5. Учебно-методическое обеспечение для самостоятельной работы обучающихся по дисциплине (модулю)** ........ 11

**6. Учебно-методическое и информационное обеспечение дисциплины (модуля)** ........ 24

6.1. Перечень учебной литературы, необходимой для освоения дисциплины (модуля) ........ 24

6.2. Перечень электронных библиотечных систем, современных профессиональных баз данных и информационных справочных систем ........ 24

6.3. Перечень лицензионного и свободно распространяемого программного обеспечения, в том числе отечественного производства ........ 25

**7. Материально-техническая база, необходимая для осуществления образовательного процесса по дисциплине (модулю)** ........ 25

**1. Перечень планируемых результатов обучения по дисциплине, соотнесенных с установленными в образовательной программе индикаторами достижения компетенций**

| Формируемая компетенция (с указанием кода) | Код и наименование индикатора достижения компетенции | Результаты обучения по дисциплине (модулю) |
|---|---|---|
| ПК-2. Способен выделять структурные элементы, входящие в систему познания предметной области (в соответствии с профилем и уровнем обучения), анализировать их в единстве содержания, формы и выполняемых функций | ПК-2.1. Знает структурные элементы, входящие в систему познания предметной области, выделяет и анализирует единицы различных уровней языковой системы в единстве их содержания, формы и функций, мир художественного произведения как культурно-эстетического феномена и литературных явлений в их структурном единстве и функциях | Обучающийся должен:<br>Знать основные теоретические понятия дисциплины и отличительные признаки языковой ситуации каждого периода истории татарского литературного языка, закономерности исторического процесса формирования татарского литературного языка, методы выполнения научно-исследовательских работ в области истории татарского литературного языка |
| | ПК-2.2. Умеет находить структурные элементы, входящие в систему познания предметной области, анализировать, синтезировать, применять системный подход в соответствии с поставленными задачами. | Обучающийся должен:<br>Уметь видеть проявление общих закономерностей развития татарского литературного языка в отдельных произведениях каждого периода, лингвистически корректно использовать методы выполнения научно-исследовательских работ |
| | ПК-2.3. Владеет навыками анализа и интерпретации литературных и языковых явлений в единстве содержания, формы и выполняемых функций | Обучающийся должен:<br>Владеть навыками выполнения историко-лингвистического анализа литературных текстов разных эпох, стилей и жанров |

**2. Цели и место дисциплины (модуля) в структуре образовательной программы**

Цели изучения дисциплины:

1) познакомить с этапами развития и особенностями истории татарского литературного языка

2) воспитывать интерес к истории народа и родному языку как средству великой духовной культуры

Дисциплина «История родного (татарского) языка» относится к части, формируемой участниками образовательных отношений.

Дисциплина изучается на 1 курсе в 2 семестре

**3. Объем дисциплины (модуля) в зачетных единицах с указанием количества академических или астрономических часов, выделенных на контактную работу обучающихся с преподавателем (по видам учебных занятий) и на самостоятельную работу обучающихся**

Общая трудоемкость (объем) дисциплины составляет 3 зач. ед., 108 акад. ч.

| **Объем дисциплины** | **Всего часов** |
|---|---|
| | **Очная форма обучения** |
| Общая трудоемкость дисциплины | 108 |
| Учебных часов на контактную работу с преподавателем: | |
| лекций | 16 |
| практических (семинарских) | 32 |
| другие формы контактной работы (ФКР) | 1,2 |
| Учебных часов на контроль (включая часы подготовки): | 34,8 |
| экзамен | |
| Учебных часов на самостоятельную работу обучающихся (СР) | 24 |

| **Формы контроля** | **Семестры** |
|---|---|
| экзамен | 2 |

**4. Содержание дисциплины (модуля), структурированное по темам (разделам) с указанием отведенного на них количества академических часов и видов учебных занятий**

**4.1. Разделы дисциплины и трудоемкость по видам учебных занятий (в академических часах)**

| **№ п/п** | **Наименование раздела / темы дисциплины** | **Виды учебных занятий, включая самостоятельную работу обучающихся и трудоемкость (в часах)** | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **Контактная работа с преподавателем** | | | **СР** |
| | | **Лек** | **Пр/Сем** | **Лаб** | |
| **1** | **Общие вопросы «Истории родного языка».** | **8** | **10** | **0** | **8** |
| 1.1 | Общие сведения об истории тюрко-татарского народа. Этапы формирования тюркских языков | 2 | 4 | 0 | 2 |
| 1.2 | История развития графических систем татарского языка | 2 | 2 | 0 | 2 |
| 1.3 | Языковые особенности текстов на рунической и уйгурской графике | 2 | 2 | 0 | 2 |
| 1.4 | Старотюркский язык текстов на арабской графике | 2 | 2 | 0 | 2 |
| **2** | **История формирования фонетической, лексической, грамматической систем татарского** | **8** | **22** | **0** | **16** |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | **литературного языка** | | | | |
| 2.1 | Историческая фонетика родного (татарского) языка. Вокализм. Консонантизм | 2 | 4 | 0 | 4 |
| 2.2 | История формирования лексической системы родного (татарского) языка. | 2 | 2 | 0 | 2 |
| 2.3 | Историческое словообразование татарского языка. | 2 | 2 | 0 | 2 |
| 2.4 | История формирования морфологической системы и грамматических категорий татарского литературного языка | 2 | 8 | 0 | 2 |
| 2.5 | История формирования синтаксической и стилистической систем татарского языка | 0 | 2 | 0 | 2 |
| 2.6 | История развития татарского языкознания | 0 | 4 | 0 | 4 |
| | **Итого** | **16** | **32** | **0** | **24** |

**4.2. Содержание дисциплины, структурированное по разделам (темам)**

Курс практических/семинарских занятий

| № | Наименование раздела / темы дисциплины | Содержание |
|---|---|---|
| **1** | **Общие вопросы «Истории родного языка».** | |
| 1.1 | Общие сведения об истории тюрко-татарского народа. Этапы формирования тюркских языков | 1. Төрки, татар һәм төрек атамалары. Аларның этник атамалар буларак кулланылышы һәм семантикалары.<br>2. Беренче төрки каганат тарихы (551-630). Икенче төрки каганат тарихы (682-743). Төркиләрдә язу барлыкка килү.<br>4. Уйгыр каганаты тарихы (745-840). Уйгырлардан калган язма истәлекләр.<br>5. Бөек Болгар дәүләте. Аның Хәзәр каганаты белән мөнәсәбәте.<br>6. Идел Болгары. Рәсми рәвештә ислам динен кабул итүнең (922) роле. Гарәп язуын куллана башлау.<br>7. Алтын Урда дәүләте. Алтын Урда чоры язма истәлекләре.<br>8. Казан ханлыгы. Башка татар ханлыклары.<br>9. XVIII–XX йөзләрдә татар дәүләтчелекләре тарихы.<br>10. Тюркологиядә төрки халыкларның кардәшлеге мәсьәләсенә карашлар.<br>11. Телләрнең генеалогик классификациясе. Телләр бүленеше. Урал-алтай телләре теориясе.<br>12. Төрки телләр һәм төрки-татар теле формалашуын чорларга бүлү.<br>13. Әдәби телнең язма һәм сөйләмә төрләре. |
| 1.2 | История развития графических | 1. Рун язулы һәйкәлләрнең табылу һәм |

| | | |
|---|---|---|
| | систем татарского языка | өйрәнү тарихы. Аларны төркемләү. Төрки руналарның генезисы.<br>2. Уйгыр язма һәйкәлләрен табу һәм өйрәнү тарихы. Ике язулы (уйгыр һәм гарәп хәрефле) истәлек буларак «Кутадгу билик».<br>3. Уйгыр язуының Идел-Чулман буенда кулланылуы. |
| 1.3 | Языковые особенности текстов на рунической и уйгурской графике | 1. Ташъязмаларны дешифровкалау. Ачышларның төрки тел белеме өчен әһәмияте.<br>2. Төрки рун алфавиты. Рун алфавитының график системасы.<br>3. Борынгы төрки нигез телгә хас сузык аваз хәрефләре, аларның саны, составы.<br>4. Борынгы төрки телдә тартык аваз хәрефләре, аларның саны, төп үзенчәлекләре.<br>5. Уйгыр алфавитының барлыкка килүе. Иске уйгыр графикасы үзенчәлекләре. |
| 1.4 | Старотюркский язык текстов на арабской графике | 1. Татарларда гарәп графикасының мәгърифәти һәм мәдәни роле.<br>2. Гарәп алфавиты үзенчәлекләре.<br>3. Гарәп язуы чорында орфография. Иске имла. Урта имла.<br>4. Татар теле тарихында латин язуы. Латин алфавитын кабул итү тарихы.<br>5. Латин графикасының үзенчәлекләре. Латин алфавитына нигезләнгән орфография. Яңалиф.<br>6. Хәзерге татар әдәби телендә кирилл алфавитын куллану. Татар язуын рус алфавитына күчерү тарихы.<br>7. Татар авазларын рус алфавиты белән күрсәтү кыенлыклары. |
| **2** | **История формирования фонетической, лексической, грамматической систем татарского литературного языка** | |
| 2.1 | Историческая фонетика родного (татарского) языка. Вокализм. Консонантизм | 1. Борынгы төрки нигез телгә хас сузык авазлар, аларның саны, составы һәм билгеләре.<br>2. Идел буендагы төрки телләрдә сузыклар күчеше. Сузыкларда сингармонизм күренеше.<br>3. Хәзерге татар телендә сузык авазларга тарихи-лингвистик характеристика.<br>4. Тартык авазлар тарихын өйрәнү алымнары, төп терминнар һәм төшенчәләр.<br>5. Тартык авазлар һәм аларның тарихы. Тартык авазлар (консонантизм) өлкәсендәге үзгәрешләр. Сөйләмдәге әйтелеш белән бәйле үзенчәлекләр.<br>6. Татар әдәби телендә фонетик |

| | | |
|---|---|---|
| | | нормаларның үсеше. Язу һәм әйтелеш нормаларын камилләштерү һәм рәсмиләштерү белән бәйле мәсьәләләр. |
| 2.2 | История формирования лексической системы родного (татарского) языка. | 1. Борынгы һәм иске төрки лексика, аларның хәзерге телгә мөнәсәбәте.<br>2. Лексик яктан татар әдәби теле үсешенең тарихи җирлеге.<br><br>3. Лексиканы тарихи-чагыштырма өйрәнүдә төп чыганаклар.<br>4. Сүзләргә лексик-тематик классификация һәм лексик-семантик классификация.<br>5. Татар лексикасы үсешендә төп семантик процесслар. Әдәби телдә күпмәгънәле (полисемантик) сүзләрнең барлыкка килүе.<br>6. Мәгънәләре бер-берсеннән ераклашкан аваздаш сүзләрнең үсеше. Исем омонимнар. Исем, сыйфат, саннардан торган омонимнар. Фигыль омонимнар.<br>7. Мәгънәдәш сүзләрнең (синонимнар) кулланылышы.<br>8. Телдә аерым сүзләрнең архаиклашуы.<br>9. Әдәби телдә алынма сүзләрнең тоткан урыны. Фин-угор телләреннән алынган сүзләр.<br>10. Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләр.<br>11. Көнбатыш Европа телләреннән һәм рус теленнән кергән алынма лексика.<br>12. Совет чоры әдәби теле лексикасында үзгәрешләр. Гади сөйләм үзенчәлекләреннән файдалану. |
| 2.3 | Историческое словообразование татарского языка. | 1. Татар телендә сүз тамыры һәм кушымчалар, аларның тарихы. Сүз тамыры.<br>2. Кушымчалар һәм аларның килеп чыгышы. |
| 2.4 | История формирования морфологической системы и грамматических категорий татарского литературного языка | 1. Язма ядкярләрдә сүз төркемнәренең грамматик мәгънәләре һәм формалары.<br>2. Исемдә сан һәм тартым категориясе тарихы.<br>3. Килеш категориясе. Төрки телләрдә килешләр.<br>4. Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатларның ясалышы.<br>5. Татар телендә төп һәм дистә саннар һәм аларның этимологиясе. Санау берәмлекләре.<br>6. Алмашлыклар һәм аларның семантик |

| | | |
|---|---|---|
| | | төркемчәләре.<br>7. Төрки телләрдә фигыль сүз төркеменең формалашу тарихы. Юнәлеш категориясе.<br>8. Наклонение категориясе (хикәяләү, боерутеләк, шарт). Хикәя фигыльләрдә заман категриясенең формалашуы.<br>9. Татар телендә аналитик заман формалары һәм аларның тарихы.<br>10. Затланышсыз фигыль формалары.<br>11. Рәвеш. Бәйлекләр. Теркәгечләр. Кисәкчәләр. Аваз ияртемнәре |
| 2.5 | История формирования синтаксической и стилистической систем татарского языка | 1. Әдәби тел һәм стильләр. Әдәби стильләрнең үсеш тенденцияләре.<br>2. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы һәм аның тел-стиль үзенчәлекләре.<br>3. Хәрәзминең «Мәхәббәтнамә» әсәре һәм аның тел-стиль үзенчәлекләре.<br>4. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасы һәм аның тел-стиль үзенчәлекләре.<br>5. «Гөлестан бит-төрки» әсәренең теле.<br>6. Мәхмүд бине Гали Болгаринең «Нәһҗелфәрадис» әсәренең тел үзенчәлекләре. Мөхәммәдьяр Мәхмүд углы әсәрләренең телстиль үзенчәлекләре.<br>7. XV – XVI гасырларда башка шагыйрьләрнең әсәрләре һәм теле.<br>8. Казан дәүләтендә рәсми канцелярия һәм дипломатия стиле. Олуг Мөхәммәд ханның эпистоляр мирасы. Ярлыклар. Сәхипгәрәй хан ярлыгы (1523). Ибраһим хан ярлыгы.<br>9. Фәнни стиль турында мәгълүматлар. Әдәби телдә канунлашу процессының барышы.<br>10. Әдәби телнең халык сөйләм теле нормаларына нигезләнүе. Әдәби телнең үсешендә диалектларның роле.<br>11. Әдәби тел һәм стильләр мәсьәләсе. Татар әдәби теле тарихында өч стиль системасы. Югары стиль. Урта стиль. Түбән стиль. |
| 2.6 | История развития татарского языкознания | 1. Каюм Насыйриның татар тел белемен һәм әдәби телне үстерүдәге эшчәнлеге.<br>2. Хәбирә Насыйриянең тел белеменә караган хезмәтләре.<br>3. Татар әдәби телен һәм фәнни стильне үстерүдә Ш.Мәрҗанинең тоткан урыны.<br>4. Татар әдәби телен үстерүдә Габдулла Тукайның роле. Тукай һәм татар әдәби теле. Г.Тукайның тел концепциясе һәм әдәби телнең халыкчанлыгы өчен көрәше. |

| | | |
|---|---|---|
| | | 5. Г.Тукайның тел осталыгы. Тукайда сатирик тел чаралары. Тукайның публицистик стильне үстерүдә эшчәнлеге.<br><br>6. Ф.Әмирханның татар әдәби телен үстерүдә тоткан урыны.<br>7. Г.Коләхмәтовның әдәби телне үстерү өлкәсендә эшчәнлеге.<br>8. Г.Ибраһимов – татар тел белемен һәм әдәби телне үстерүче.<br>9. Г.Исхакыйның татар милли әдәби телен үстерүдәге эшчәнлеге.<br>10. Совет чорында татар тел белеменең үсеше һәм уку йортларында телне гамәлгә кую мәсьәләре.<br>11. Революциядән соңгы әдәби телнең лексик нормалары. Сүзлек хәзинәсен эшкәртүдә рәсми оешмаларның роле.<br>12. XXI гасыр башында татар тел гыйлеменең үсеш юнәлешләре. |

Курс лекционных занятий

| № | Наименование раздела / темы дисциплины | Содержание |
|---|---|---|
| **1** | **Общие вопросы «Истории родного языка».** | |
| 1.1 | Общие сведения об истории тюрко-татарского народа. Этапы формирования тюркских языков | Основные направления изучения истории языка: историческая грамматика и история литературного языка. Историческая грамматика татарского языка, ее составные части, основные источники для изучения. Методы изучения истории языка. Транскрипция и транслитерация. Древние тюрки и тюркские племена Евразии. Тюркский каганат. История Уйгурского каганата. Великая Болгария. Его отношения с Хазарским каганатом. Волжская Булгария. Золотоордынское государство. Казанское ханство. Другие татарские ханства. Татары в XVIII-XX вв. История государственности. Генеалогическая классификация языков. Тюркское языковое родство. Этапы формирования тюркских языков и тюрко - татарского языка. Письменные и разговорные разновидности литературного языка. |
| 1.2 | История развития графических систем татарского языка | Памятники древнетюркской рунической и уйгурской письменности. История обнаружения и изучения памятников рунической письменности. Сгруппируйте их. Генезис тюркских рун. История открытия и изучения памятников уйгурской письменности. Памятники с двумя надписями (уйгурскими и арабскими буквами)<br>"Кутадгу билик". Использование уйгурской |

| | | |
|---|---|---|
| | | письменности в Поволжье. Дешифровка рукописей. Значение его открытий для тюркского языкознания. Графика древнетюркского языка. |
| 1.3 | Языковые особенности текстов на рунической и уйгурской графике | Тюркский рунический алфавит. Графическая система рунического алфавита. Древнетюркская основа-гласные буквы, их количество, состав. На древнетюркском языке<br>буквы согласных звуков, их количество, основные характеристики. Появление Уйгурского алфавита. Особенности староуйгурской графики. |
| 1.4 | Старотюркский язык текстов на арабской графике | Старотюркская графика. Просветительская и культурная роль арабской графики у татар. Особенности арабского алфавита. Орфография в период арабской письменности. Старое написание. Средний имля. |
| **2** | **История формирования фонетической, лексической, грамматической систем татарского литературного языка** | |
| 2.1 | Историческая фонетика родного (татарского) языка. Вокализм. Консонантизм | Древнетюркская основа-гласные звуки, их количество, состав и признаки. Переход гласных в тюркских языках Поволжья. Явление сингармонизма в гласных. Историко-лингвистическая характеристика гласных в современном татарском языке. Методы изучения истории согласных звуков, основные термины и понятия. Гласные и их история. Изменения в области согласных звуков (консонантизм). Особенности, связанные с произношением в речи. Развитие фонетических норм в Татарском литературном языке. Вопросы, связанные с совершенствованием и оформлением норм письменности и произношения. |
| 2.2 | История формирования лексической системы родного (татарского) языка. | Древняя и старотюркская лексика, их отношение к современному языку. Исторические предпосылки развития лексики татарского литературного языка. Основные источники по историко-сравнительному изучению лексики. Лексико-тематическая классификация и лексико-семантическая классификация слов. Основные семантические процессы в развитии татарской лексики. Возникновение многозначных (полисемантических) слов в литературном языке. Развитие созвучных слов, значения которых отдалены друг от друга. Архаизация отдельных слов в языке. Место заимствований в литературном языке. Слова из арабо-персидских языков. Заимствованная лексика из западноевропейских языков и русского языка. Изменения в лексике литературного языка советского периода. Народно-разговорный язык как основной источник лексики. Просторечная лексика. |
| 2.3 | Историческое словообразование татарского языка. | Историческая морфемика и морфонология. Корни слов и аффиксы в татарском языке, их история. Корень слова. Аффиксы и их происхождение. |
| 2.4 | История формирования морфологической системы и | Историческая морфология. Грамматические значения и части речи в письменных памятниках. Категория |

| | | |
|---|---|---|
| | грамматических категорий татарского литературного языка | числа в именах существительных. История категории принадлежности. Категория падежа. Имена прилагательные. Происхождение имен прилагательных. Имена числительные в татарском языке и их этимология. Единицы измерения. Местоимения и их семантические подгруппы. История формирования глаголов в тюркских языках. Категория направленности. Категория наклонения (повествование, повеление-желание, условие). Категория времени у глаголов повествовательного наклонения. Формы аналитического времени в татарском языке и их история. Формы безличных глаголов. Предлоги. Союзы. Частицы. Звукоподражательные слова |

**5. Учебно-методическое обеспечение для самостоятельной работы обучающихся по дисциплине (модулю)**

Порядок историко-лингвистического, историко-фонетического, историко-морфонологического анализов.

Тарихи-лексик анализ

Төрле чорларга караган язма истәлекләрнең сүзлек составын тикшергәндә түбәндәгеләргә игътибар ителә:

1. Текстның эчтәлегенә төшенү өчен, андагы сүзләргә аңлатма биреп чыгу һәм контекстта аларның мәгънәсен ачыклау;
2. Хәзерге әдәби телдә очрамый торган сүзләргә аерым аңлатма бирү, аларның кулланышын тарихи чор белән бәйләп карау;
3. Тексттагы сүзләрнең генетик чыганагын (төрки, гарәп, фарсы һ.б.) күрсәтү;
4. Төрки сүзләрнең кайбер этимологик якларына тукталу, төрле чагыштырулар үткәрү;
5. Сүзнең контексттагы мәгънә төсмерен, аның стилистик үзенчәлекләрен ачыклау.

Димәк, монда саф лексик якны гына түгел, бәлки семантик һәм стилистик үзенчәлекләрне дә искә алу әһәмиятле. Бу очракта сүзләрнең мәгънәдәшлеге – синонимик вариантлар, эмоциональ- экспрессив, күчерелмә мәгънәдәге сүзләр, вульгар һәм фамильяр лексика, алардагы стилистик төсмерләр тикшерелә. Шул ук вакытта әдәби телнең язма һәм сөйләмә формаларына хас сүзләрне дә аеру таләп ителә. Гомумән, тарихи-лексик анализда семантикага, стилистикага, сүзләрнең үзгәрешләрен аңлатуга бик нык басым ясала. Төрле төрки төркемнәр (болгар, кыпчак, угыз, чыгтай, уйгур һ.б.) өчен хас лексикага да билгеле күләмдә игътибар ителә.

Тарихи-фонетик анализ

Бу анализ фонетик күренешләрнең төп асылын ачуны максат итеп куя. Анда түбәндәгеләргә игътибар ителә:

1. Иске татар әдәби телендәге авазларга (вокализм һәм консонантизм системасына) характеристика бирә белү;
2. Аваз тәңгәллекләрен, фонетик чиратлашулар һәм аларның фонологик ролен билгеләү;
3. Аерым төрки телләр төркеменә хас фонетик үзенчәлекләрне аера белү;
4. Сүзләрдәге басым һәм иҗек төзелешен ачыклау.
5. Иске татар теленең фонетик системасында төп тенденцияләрне күрсәтү.

Фонетик анализны уңышлы башкаруда тарихи-чагыштырма метод зур урын тота. Анализ барышында теге яки бу төркемгә караган үзенчәлекләрне аерып бирү әһәмиятле. Мәсәлән: Болгар телләренә хас үзенчәлекләрне билгеләгәндә, ротацизм (күр/күз, сөр/сөз), ламбдаизм (калак – кашык) күренешләренә, саңгырау авазларның зур урын тотуына, дифтонглар үсешенә, кайбер авазларның ешрак кулланышына һ.б. игътибар ителә.

Кыпчак телләре турында сүз барганда, анда тар сузыкларның кушымчаларда иренләшмәве, дифтонгларның киң таралуы, озын сузыкларның булмавы, сүз башында яңгырауларның да, саңгырауларның да кулланылуы (балта, бал, тел, кил), җ урынына й нең актив йөрүе һ.б. искә алына.

Угыз төркеменә хас үзенчәлекләрне ачыклаганда, түбәндәгеләргә тукталу әһәмиятле: сүз башында тартыкларның яңгыраулашуы (гөр, гөз, дил), сүз ахырында [гъ] – [г] авазларының булуы (даг, бәг), сүзнең башында тартыкларның төшүе (ол, олур), сүз уртасында [гъ] – [г] авазларының кулланылмавы (килгән урынына гилән, алган урынына алан) һ.б.

Тарихи-грамматик анализ

Бу анализда, тарихи чорга бәйләнешле рәвештә, түбәндәгеләргә игътибар ителә:

1. Грамматик күренешләрнең (морфологик, синтаксик) мәгънәләрен һәм кулланышын аңлатып бирү;
2. Хәзерге телдәге формалар белән чагыштыру;
3. Кайсы төрки телләр төркеменә кергәнен күрсәтү;
4. Грамматик категорияләрнең системасын күзаллау;
5. Архаик формаларның диалектларда кулланылу-кулланылмау очракларын аңлату.

Элекке язма әсәрләрдә хәзерге тел өчен характерлы булмаган үзенчәлекләр шактый еш очрый. Мәсәлән: барайын – барыйм (теләк фигыль), төшкәй – төшәр, барысарым – барачакмын, күрисәрем – күрәчәкмен (киләчәк заман фигыльләр), бармага – барырга (инфинитив), алдачысән, булдачысән – алачаксың, булачаксың (киләчәк заман сыйфат фигыль), күрмеш – күргән (үткән заман сыйфат фигыль).

Тарихи-стилистик анализ

Тарихи-стилистик анализ язма истәлекләрдәге образлы сүрәтләү алымнарына, эмоциональ-экспрессив чараларга, аралашуның төрле сфераларында кулланыла торган тел үзенчәлекләренә, сөйләмнең функциональ кулланылышына характеристика бирүне күздә тота.

Шул рәвешчә, тарихи-лингвистик анализ текстның жанр һәм стиль үзенчәлекләре белән тыгыз бәйләнештә алып барыла.

Студентларга мөстәкыйль эш күнекмәләрен үстерергә ярдәм итә торган язма текстлар тәкъдим ителә. Һәр текстны төрле яклап анализларга мөмкин.

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

Индивидуаль эш өчен биремнәр

1нче бирем. Борынгы төрки телдә язылган истәлекләрдән өзекләрне хәзерге телгә мөнәсәбәттә күзәтегез, тикшерегез: 1) аваз үзгәрешләре;
2) грамматик формалар; 3) сүзлек составы.

Күлтәгин язмасы (732 – 735 еллар)

...Ерак әрсәр йаблак агы бирүр. Йагык әрсәр әдгү агы бирүр. Тәрҗемәсе:

...Ерактагыңа начар бүләк бирер(ләр), Якындагыңа затлы бүләк бирер(ләр).

* * *
Чыгаң будуныг бай кылтым, Аз будуныг үкеш кылтым. Тәрҗемәсе:

Ярлы халыкны бай кылдым, Аз халыкны күп кылдым.

* * *
...Иллег будун әртем, –
Илем амти каны?.. Каганлыг будун әртем, – Каганым каны?..
Тәрҗемәсе:
* * *
...Каным каган сүсе бүре әрмеш, Йагысы коң тәг әрмеш.

...Дәүләтле (илле) халык идем, –
Илем инде кайда?.. Каганлы халык идем, – Каганым кайда?

...Атам каган гаскәре бүре (кебек) иде, Дошманнары куй кебек иде.

* * *
...Кыркыз, курыкан, утыз татар, кыдан, татабы – күп йагы әрмеш. Тәрҗемәсе: Кыргыз, курыкан, утыз татар, кыдан, татабы – бары да дошман иде.
* * *

...Каның субча йөгертте, Сөңүкең тагча йатды, Бәгелег ари углың кол булты, Сөлек кыз оглы коң булты... Тәрҗемәсе:

* * *

...Каның суча (су кебек) акты, Сөягең таудай ятты (өелде),
Бәктәй саф (затлы) ул(лар)ың кол булды,
Сөлектәй кыз балаларың кәнизәк булды...

Огуз ягы ордуг баеды. Күлтигин, өгсиз акын бинип, токуз әрин санчды, ордуг бирмәди. Өгим катун улаю өгләрим, әкәләрим, кәлиңүним, кунчуйларым, бунча йәмэ тириги күн. болтачы әрти, өлүги юртда йолта яту калтачы әртигиз! Күлтигин йок әрсәр, коп өлтәчи әртигиз! Эним Күлтигин кәргәк болты, өзим сакынтым:

Көрүр көзим көрмәз тәг,
Билир билигим бәлмәз тәг болты, өзим сакынтым. Өд тәңри ясар, киси оглы коп өлгәли төрүмис.

Тәрҗемәсе:
Угыз гаскәре урдабызга һөҗүм итте. Күлтигин ак Өгсизинә атланып, (угызларга

ташланды), аларның, тугыз батырын кадап үтерде, урданы бирмәде. Анам – хатын, анын артыннан килүче сез дә: атамның башка хатыннары – аналарым, апаларым, кәләшләрем, сеңелләрем, – сез күпме булсагыз, барыгыз да куркыныч астында идегез: тере калсагыз, кол булыр идегез, үлсәгез, гәүдәләрегез җирдә, юлларда аунап калыр иде. Әгәр Күлтигин булмаса иде, сезнең күбегез һәлак булыр иде! Энем Күлтигин һәлак булды, үзем хәсрәтләргә баттым:

Күрер күзләрем күрмәс булды,
Акылым-зиһенем катып калгандай булды, Үзем хәсрәтләргә баттым.
Вакыт-чаманы тәңре билгели,
Адәм балалары бер үләр өчен туалар.

Күлтәгин истәлеге. Кече язма

1. Тәңредәй күкләрдә яратылган зирәк төрки каган булып бу вакытта тәхеткә утырдым. Сүземне төгәл ишетегез: барыгыз - кече туганнарым, улларым. биредәге оям халкы, көньякка - шад - апыт бәкләр, төньякка - таркат - боерык бәкләр, утыз
2. тугыз угыз бәкләре халкы! Бу сүземне яхшы ишет, ныклап тыңла. Алга - кояш чыгышына, уңга - көн уртасына, артка - көн батышына, сулга - төн уртасына кадәр сузылган җирдә яшәүче халыкны тупладым, күбәйттем. Инде
3. хәзер борчу юк, төрки каган Өтүкән ешлыгында (иңкүлегендә) булса, Илгә авырлык булмас. Алга, көнчыгышка, Шантун даласына кадәр сугыштык, диңгезгә аз гына җитмәдек, уңга, көнчыгышка, Тугыз Әрсәнгә кадәр сугышып бардык, Түпүткә җитәргә бик аз калды, артка - көнбатышка Йинчү үгүз
4. кичеп, Тимер - Капыгка кадәр сугыштык, төньякка Баерку җиренә кадәр сугышып бардык. Шул кадәр җирләргә йөрттем. Өтүкән ешлыгыннан да яхшы урын булмас, илне тотачак жир Өтүкән ешлыгы иде. Бу жирләрдә урнашып, табгач халкы белән аралаштык.

Кули-Чору истәлек язмалары Көнбатыш як

(1) ... чыкан Тониүкук исеме бирделәр.
(2) ... без күтәрелгәч, Ышбара-чыкан Кули-Чор булды ... Кули-Чор Тониунук ...
(3) ... [Элтериш] – каган дәүләтендә, картайгач, әйбәт бина [һәйкәл] күрде. Бөек Кули-Чор сиксән яшь яшәгәч, вафат булды ...
(4) ... үзенең күк аты, киемнәре, кыюлыгы һәм батырлыгы ... төрки халкына ...
(5) ... үзенең ярдәмчесе белән бергә дошман булгач, [Кули] Чор җиңде һәм үтерде, аның улларын, аның хатыннарын ... әсир итте...
(6) ... дәүләт белән идарә итте. Җир ... Кули-Чор төрки халык һәм бәкләрне ...
(7) ... зирәк иптәш, батыр һәм яхшы [иптәш] булганлыгы хакына.
(8) ... Ышбара Билге Кули-Чор кешеләр ...
(9) ... сугыш вакытында ул гаскәр белән җитәкчелек итте, [җанварларга] сунар вакытында ул ... сыман булды ...

Моюн-Чору истәлек язмалары. Төньяк ягы

(1) Теңридә болмыш, Ил-итмиш – Билге- каган ... Төлес ...
(2) Өтүкән тирә-ягы ... аларның дәүләте шушы таулар арасына урнашкан, суы селенга иде, анда аларның дәүләте [чәчәк атты] ... алар шунда яшәделәр, күчмә тормыш ... алып бардылар ...
(3) ә калган халык уйгурларның ун, огузларның тугыз кабиләсе өстеннән йөз ел хакимлек иттеләр ... Оркун елгасы янында ...
(4) төрки-кыпчаклар илле ел яшиләр. Ул чакта төрки дәүләтендә минем егерме алтынчы яшемдә ... [каган] бирде [миңа, минем әтиемә] ... шуннан бойла ... [минем әтием] ...

(5) әйләнеп кайткач, туктап [лагерь булып], ә мин үземнең тугыз огуз халкын җыйдым һәм берләштердем. Минем әтием Күк билге каган ...
(6) гаскәрләр белән китте, минем үземне меңбашы итеп алдан көньякка җибәрде, Кейредан, мин борылырга тиеш идем ...
(7) [төркиләрне] үз дәүләтемә буйсындырып, мин тагын да гаскәрләр белән киттем. Кейре түбәсендә һәм Биркү өч [елга] янында мин хан гаскәрләре белән бәрелештем, анда ...
(8) мин тиз генә аларны куа киттем. Без Кара-комны үттеп [Коба] Көгур һәм Көмүр тавы һәм Яр елгасы янында өч байраклы төрки халкын ...
(9) Озмыш-тәгин хан иде. Сарык елында [743 елда] мин походка кузгалдым. Икенче сугышны мин [төркиләргә] беренче айның алтынчы числосында оештырдым ... Озмыш-тегинны ...

(10) мин әсир иттем, аның хатынын мин үземә алдым. Төрки дәүләте [халкы] алда да шулай юк ителәчәк. Шуннан соң, Тавык елында [745 елда] халык ... бу хакта белгәч,
(11) Халык [өч карлук] усал ниятләр белән качты, күчеп китте һәм көнбатышта [көнбатыш төркиләрнең] ун кабиләсенә барып кушылды ... Дуңгыз елында [747 елда] мин аларны тар-мар иттем ... Тай Билге Тутукны ...
(12) Ул ябгу титулы белән атады. Шуннан соң минем әтием вафат булды. Гади халык [минем хакимлеккә] бирелде. Мин аларны җиңдем ...

2 нче бирем. Борынгы төрки телдән иске төрки телгә күчү чорында язылган истәлекләрдән берничә мисал. Аларны хәзерге телгә мөнәсәбәттә күзәтегез, тикшерегез: кайсы сүзләр хәзерге әдәби телдә башка сүзләр белән алмашынганнар?

1. Сәүеглене сәүмәз, кәдик тәг качар! Качыглыга йабшыр, адагын кучар!
Ара көрсә, йүгрүр бәзәнип уду, Ара күрмәдүк тәг кылур йәр коду. Ара көрсә, әүрүр йәнә тәрк йүзүн. Ауаглар нәчә колса, бәрмәз өзин.
Хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәсе:

Сөйгәнне сөймәс, кыргый җәнлектәй качар! (Аннан) качканга ябышыр, аягына уралыр! Я күрсә, качар гәүдәсе артына,
Я күрмәмешкә салышыр, кәефе киткәндәй итәр. Я күрсә, тагын йөзен яшерер.
Эзләүчеләр күпме эзләсә дә, үзен бирмәс.

(1069 нчы елда Юсуф Баласагунлы тарафыннан язылган «Кутадгу белек» – «Бәхетлелек белеме» – әсәреннән. С.Е. Малов. Памятники древнетюркской письменности. М.-Л., 1951, 240–241 нче битләр.)

2. 1068–1072 нче еллар арасында Мәхмүт Кашгариның «Диване лөгать әт- төрек» төрки сүзләр җыентыгыннан берничә мисал.

а) Өкүз адакы болгинча, бузагу башы босаик. Хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәсе:
Үгез аягы булганчы, бозау башы булу яхшырак.

б) Этил суы ака турур, Кая түбе кака турур,

Балык тәлим, бака турур, Көлүң такы күшәрүр.
Хәзерге татар теленә тәрҗемәсе:

Идел суы агып тора,
Кыя төбен кагып тора, Балыгы күп, бака була, Сулары да тулып тора.

3 нче бирем. Иске төрки тел үрнәкләрен укыгыз. Хәзерге татар әдәби теле белән чагыштырыгыз. Телдә булган үзгәрешләрнең, үсешенең сәбәпләрен аңлатыгыз.

1. Зөләйха беркөн ятып оер иде, Йосыфның сурәтен дөшдә күрде.
Күрүбән, һаман сәгать гашыйк булды. Аглаюп уянубән кәлүр имди.
Атасы сорар, әйдер: «Нә агларсән? Күңелендә нә кәчәр, нә теләерсән? Дөшең эчрә нә күреп арзуларсән? Морадыңны мәңа игълан кылгыл имди».
Хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәсе:

Зөләйха беркөн ятып йоклаган иде, Йосыфның сурәтен төшендә күрде. Күреп, шул ук вакытта гашыйк булды, Елап уянып килә иде.
Әтисе сорады, әйтте: «Нигә елыйсың? Күңелендә ни кичерәсең, нәрсә телисең? Төшеңдә ни күреп өметләнәсең? Максатыңны миңа да белдер».

(1212 нче елда Кол Гали тарафыннан язылган «Йосыф вә Зөләйха» әсәреннән.)

2. Бир султанның үч оглы бар иди. Иккиси узун бойлы са- хипҗамал, дагы бири кыска бойлы иди. Бир күн султан бу кыска бойлы оглына хәкарәт көзи билә бакты. Олган фирәсәт билен билди дагы әйтти: «Әй ата, узун бойлы ахмакдан кыска бойлы гакыйль яхшырак дурур».
Хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәсе:
Бер солтанның өч улы бар иде. Икесе озын буйлы матурлар, тагы берсе кыска буйлы иде. Беркөн солтан бу кыска буйлы улына кимсетү күзе белән карады. Улы акыллылыгы (интеллигентлыгы) белән белде дә әйтте: «Әй ата, озын буйлы ахмактан буе кыска акыллы яхшырак».
(XIV йөздә Сәйфи Сарай тарафыннан язылган «Гөлстан» әсәреннән.)

3. Бу китабка «Нәһҗ-әл-Фәрадис» дею исм кылынды, мәгънәсе уҗмахларның ачык юлы темәк олур... икенче күниндә йылга йети йүз еллик төкузда Сарай шәһариндә эрди... Кылгу- чы әл-галим әл-Раббани вәл- Алимәс-Самадани, әл-устад әл-мут-лак... Мәхмүд бин Әли бин әс-Сараи мәншәән вәл-Булгари мүвәлләдән вәл-Курдари.

Бу китапка «Нәһҗ-әл-Фәрадис» дип исем кушылды. Мәгънәсе «Оҗмахларның ачык юлы» булыр. Җиде йөз илле тугызынчы елның икенче көнендә Сарай шәһәрендә иде... Кылучысы (булдыручысы) алла белгече, бәхәссез галим Мәхмүт бин Әли, чыгышы белән бин Сарай, тумышы белән Болгари һәм Курдардан.
(Мәхмүт бин Әли тарафыннан XIV йөздә язылган истәлек.)

4 нче бирем. Иске татар әдәби теле үрнәкләрен укыгыз. Анда ни өчен гарәп-фарсы

сүзләре күбәя бара, аңлатыгыз.

1. Кем кулындин килгәнечә кыйл яхшылык, Сәңа беркөн тәкый килгәй яхшылык. Богдайдыр дип илгә сатмагыл саман,
Кем яманлигъ кыйлса, ул яманлигъ кыйлур һаман. Сән яхшылык кыйл, яхшылыкта бар мәза,
Кем яманлигъ кыйлса, ул табкай җәза.
Кем егылганда, кулын тот бер моңлының. Ул тәкый тоткай кулың беркөн синең.
С а м а н – кибәк яки салам, м ә з а – файда, уңай.
Бу өзек XVI йөз урталарында Казан, Болгар шәһәрләрендә яшәгән Мәхмүд Хаҗи улы Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдән» – «Егетләр бүләге» – әсәреннән.

2. Мөхиб дуслар, хикмәтне әйтмеш көндә Сиксән сигез ирде тарих ул көн мең дә, Әйтелде шәһре Болгар кәндләрендә,
Гасый җаны Мәүлә Колый сүзли, дуслар... Гафләт берлә үтде, дуслар, булган яшем, Хәсрәт берлә тынмай акар күздин яшем,
Язык берлә тулды мәнем эчем, тышым, Соруг булса, мән кол, анда нә айгаймән. Юкдыр мәнем хакка лаек кылган эшем, Дөнья өчен булган ирмеш һәм сагышым, Үкенеч берлә үтде дәхи яз вә кышым,
Соруг булса, мән кол, анда нә айгаймән... Нәфес-һәвәс йиле берлә ярышмышмән,
Гафләт җамын алар берлә ярышмышмән, Дөнья эчрә гаҗәп илгә карышмышмән,
Соруг булса, мән кол, анда нә айгаймән... Яраткан дуслар, бу хикмәтне әйткән көндә Сиксән сигез иде тарих ул көн мең дә,

Әйтелде Болгар шәһәре җирләрендә,
Гөнаһлы Мәүлә Колый сөйли, дуслар...
Наданлык белән үтте, дуслар, булган яшем, Хәсрәт белән тынмый агар күздән яшем,
Кайгы белән тулды минем эчем, тышым,
Сорау булса, мин – кол, аңа нигә ачуланыйм... Юктыр минем аллага лаек кылган эшем,
Дөнья өчен булган икән һәм сагышым, Үкенеч белән үтте тагын яз һәм кышым,
Сорау булса, мин – кол, аңа нигә ачуланыйм... Кызыксыну җиле белән ярышкан мин,
Наданлыкны шуның белән ярышканмын (кыйнаганмын), Дөнья эчендә гаҗәп илгә туры килгәнмен,
Сорау булса, мин – кол, аңа нигә ачуланыйм...

XVII йөзнең соңгы яртысында яшәгән Мәүлә Колый әсәреннән. Ислам динен кабул иткән халыкларда ел санын «һиҗри» системасы белән йөрткәннәр. Андагы 1088 нче ел хәзерге милади системасы буенча 1677 нче елга туры килә.

3. Екет булсаң, екетлек күргәз илгә, Мәхәббәтлек путасын багла билгә; Виреп даим тәсәддык әйлә ихсан,
Сиңа куңыш адәмнәр улса ноксан. Гаделлек кыйл, ул имде әһле вәфа,
Берәүгә бер тузан тик кыйлма җәфа. Димәгел бер кешегә сән ачыйг тел, Әгәр дир ирсә адәм, сән аңа көл.

Хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәсе:
Егет булсаң, егетлек күрсәт илгә, Мәхәббәтлек бавын бәйлә билгә; Биреп даими сәдака, изгелек ит, Сиңа күрше кеше булса ярлы.
Гадел бул, ул булыр сүздә тору.
Берәүгә тузан тикле кыйлма җәфа. Әйтмә берәүгә дә: «Син ачы тел»,
Әгәр башкалар әйтсә, син аннан көл.

XVIII йөз ахыры – XIX йөз башында яшәгән Утыз Имәни әсәреннән.

4. Буның тәмсиленә бән бер хикәят Бәян идәм, ишетсәң, кыйл дираять. Будыр чыкмыш ике ахмак сәфәргә, Ирешмешләр мәкяне бер хәтәргә.
У йирдә бәс кыймай диб истирахәт,
Бере диер: «Бән торыйм, сән барып ят! Бәс андин сән торырсың, бән ятаем,
Чү, дошман кәлсә, канине батаем».
Хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәсе:
Моңа охшатып, мин бер хикәят әйтәм, Әйтәм, син ишет, белеп кал.
Бу – ике ахмак сәфәргә чыкканнар.
Барып җиткәннәр бер бик хәтәр урынга. Шунда алар төрле уй юрый башлаганнар. Берсе әйтә: «Мин торыйм, син элек ят!
Аннан син торырсың, мин ятармын, Чү, дошман килсә, канына батаем».

XIX йөз урталарында яшәгән Һибәтулла Салихов  шигыреннән.

5 нче бирем. «Кисекбаш» китабыннан алынган бу өзекне хәзерге татар әдәби теленә күчерергә.

Ғали орды әлене зөлфиқара Уйур икән бу диюне қыла парә Кире қайтты үзи әйтүр йа Ғали Тәңре арсланым теди сәне wәли
Уйур диюне үлтермәк ирлек ләгел Йаман ат берлә йөрмәк ирлек дәгел Имди син уйур диюне үлтерерсен Ғаләмне кәндүзинә көлдерерсен Нағрә орды бер көзен уйғанмады Нағрә аны җанына бойанмады Икеләнчи нагрә орды ул ғазый Йанғурады таꜧ таш җөмлә йазы
Ул дию уйꜧанды да түрт йару бақар Күб сүз сүзләр аꜧзындыйн утлар сачар Сәнме кәлдең йә Ғали дошманымыз Сәнең әлендин чыкармы җанымыз.
Түбәндәге сүзләргә фонетик, лексик, грамматик яктан тарихи- лингвистик анализ ясарга: әлене, зөлфиқара, уйур, парә, әйгүр, тәңре, үлтермәк, дәгел, үлтерерсен, көлдерерсен, бойанмады, газый, йазы, түрт, бокар, сүзләр, агзындыйн сачар, әлеңдин.

6 нчы бирем. 1) Хәзерге әдәби телдә бирергә; 2) барусарым, күрүсәрем, зөлфиқары, мәнзилә, киселмеш, китәр, илә, атыны, атым, илгәрү сүз төркемнәре ягыннан аерырга һәм грамматик анализ ясарга.

Ғали әйтүр чара йок барусарым Башымꜧа йазмушымны күрүсәрем Менде аты багладу зөлфиқары Хәсән илә Хөсәйен қылды зары Ғалине озаттылар бер мәнзилә Утыз өч мең сахабә җөмлә белә Ғали китәр ол киселмеш баш илә Сахабәләр кайттылар күз йәш илә Ғали сорар ол дәм дөл-дөл атыны
Барыр ул кисек баш китәр һәм андин қаты Қанаты бардыр тикәйсен ки очар
Уқатым дөл-дөлдин илгәрү китәр Уқыр мосхәфне һәр дәм хәтем итәр Тағ таш йитмәс йумарлануб китәр.
«Кисекбаш китабы».

7 нче бирем. Текстка тарихи-лексик анализ ясарга, элекке фонетик, грамматик үзенчәлекләрне (қылды ирсә, йәйүб, кәлең, чуқ, булмадық, камусени, қорд, чықарды, улыб) күрсәтергә һәм аларны аңлатып бирергә.

Йағқуб әйдер әгәр уйлә улур исә Йосыфи қорд йәйүб қылди исә Әꜧзасендән берәр нәснә қалды исә Ул әғзани мәңа алуб кәлең имди Анлар әйдер йа баба чуқ арадук Унуламыз ул

арада чук истәдек Әμзасендән һич нәснә булумадык
Қамусени ул корд йэмеш дирләр имди Канлу күңләк қуйынундан чықардилар Йағқуб сәүчи алдыгә кәлтүрдиләр
Қаны берлә Исраилә күстәрдиләр Аны күреб бихуд улыб дүшәр имди
«Кыйсса-и Йосыф»

8 нче бирем. Текстка тарихи-грамматик анализ ясарга, хәзер искергән формаларны татар телендәге диалектлар белән чагыштырырга һәм аларга аңлатма бирергә.

Ул қолы учсуз сатыйн алдачи сән Аны сатыб үкүш ниμмәт булдачи сән Мөлек вә дәүләт ийәси булдачи сән
Ул сәбәбдән үкүш рахәт күрнүр имди… Малик әйдер бу қолмыдыр бәйан әйләң Нә мәгнәдин сатарсыз аны сөйләң
Нә сәч қылды нишә качди дугры сөләң Гаклы күрке сездән даμы артық имди Анлар әйдер һич гөм ансыз байық қолдыр Қолымызның үч дөрлү ғәйбе вардыр Уғрыдыр йаланчидыр қачқучидыр
Бу үч дөрлү ғәйбе берлә алғыл имди
«Кыйсса-и Йосыф»

9 нчы бирем. Идел буенда иҗат ителгән эпитафик язмаларның тел үзенчәлекләре турында сөйләгез, аларны өйрәнгән галимнәрнең хезмәтләрен күрсәтегез һәм андагы карашларга кыскача анализ ясагыз.

Йекетләр күрке күңелләр үзәке Ғалимларны ағырлаμан йәтим тол үксүзләрни асраμан Муса уғылы алтынчы Шәһидулла зиярәте торур қылсун… рабиғ эл-әүүәлниң уртасы тарих 717
Болгар шәһәреннән табылган ташъязма, 1317 ел.

10 нчы бирем. Сораулар буенча әңгәмә: 1) XII-XIII гасырларда иҗат ителгән ядкарьларне санап күрсәтегез. Стиль үзенчәлекләренә карап аларны төркемләп чыгыгыз. Ул чорда әдәби телдә нинди стильләрне дифференцияләп була? 2) XIII гасырда төзелгән нинди сүзлекне беләсез, әдәби тел нормаларын үстерүдә ул нинди урын тота? Андагы лексик хәзинәгә анализ ясагыз. 3) Алып, арыслан, әл, үкүш сүзләренә лексик-семантик һәм этимологик анализ ясагыз.
4) Һиммәт, фәригъ, рәва, мәлик, камуг, гокъба, гыймарәт, мәнзил

сүзләренә аңлатма бирегез, ул сүзләрнең тарихи чыганагын күрсәтегез.

11 нче бирем. Алынган өзекләрне хәзерге татар әдәби телендә языгыз. Лексик, фонетик һәм грамматик яктан анализ ясагыз. Бу тексларда нинди төрки язма традицияләр чагыла? Шуны аңлатып бирегез.

Йитеп килде йазылар тағлар аша Қыйлу таμларга ташларға тамаша Күрер кем таμ үзәрә хуш чәчәкләр
Ачылмыш зандуваҗлар қаршы сайрар Кәлеп йаз көнләр ул қызлар хуш анда Тамаша қыйлур ирмешләр хуш анда Бу Шавыр йитмеше вақытында тағлар Чәчәк ачылып йәшәрмеш иде бағлар Алуб ташлар чәчәкләр йидги рәнге Бере сарығ бере ал бере зәңги
Котб. «Хөсрәү вә Ширин», 1342 ел.

12 нче бирем. Текстны хәзерге әдәби телгә күчерергә, искергән сүзләргә һәм формаларга аңлатма бирергә.

Ахурда бер аты бар әлгәбирмәз Азақы тупрақынга йил ийәрмез Тимер тик тойнағы тағларқазар ул Йите дәрьяныбер күлчә йөзәр ул Замана йаңлыйғ аның йөргеше чың Узар йолдызны төн тик өзсә тезген Ирер Шәбдиз аты рәнге төн тик Сәрвәр ғайат аны ул йөзе көн тик Ни Ширин тик кеше күрде бу күзем Ни Шәбдиз йаңлыйғ ат ишетте үзем
Котб. «Хөсрәү вә Ширин», 1342 ел.

13 нче бирем. Текстта элекке лексик һәм грамматик формаларга игътибар итегез. Рузкяр, туар, үкүш, қазғулық, заиғ булғай, әхвалене, тәқый, йимәде, аләт, һәмишә, зарилық сүзләренә аңлатма бирегез.

Рузкяр эчендә бер хужа бар иде. Малы-туары үкүш иде һич уғылы қызы йуқирде. Һәмишә қазғулык булыр ирде кем. Монча ниғмәт хақ тәгалә мәңа бирде. Мән үләр булсам малым җөмләсе заиџ булғай тип қазғурыр ирде.
Нәчә көнгә тикле тәғам йимәде. Кәөндин көн қазғусы зиадә булды. Ни кем алтын көмеш энҗү мәрҗән аләтләре бар ирде. Җөмләсен дәрвишләргә сәдака қылды. Милкендә һичнәрсә куймады. Тәқый төнлә иртәгәтике тәғать вә ғыйбадәт кылыр иде. Тәқый көндез руза тотар ирде. Һәмишә йығламақ берлә ха тәџаләгә зарилық берлә тәүбә берлә бу көнләри кәчерде.

Мәхмүд бине Гали. «Нәһҗел-фәрадис», 1358 ел.

14 нче бирем. XIV йөз әсәрләрендә тезмә һәм чәчмә сөйләмнең кушылып килүен күзәтегез. Алынган өзеккә лексик, фонетик анализ ясагыз.

Лоқман хәкимгә сордылар: «Әдәбне кемнән үгрәндең?» Әйтте: «Әдәбсезләрдән, бақтым аларның әфғаленә - қайсы хәрәкәт кем мәңа хуш килмәде аннан ихтираз қыйлдым»
Әгәр уйнап кеше бер хәрф әйтсә Алыр аннан белек әһле нәсыйхәт Килер ахмақ Колаџына уйынчақ Уқыр булсаң йөз илле баб хикмәт
С. Сараи. «Гөлстан», 1391 ел.

15 нче бирем. Тексттагы сүзләргә лексик-семантик анализ ясагыз, тел-стиль чараларына аңлатма бирегез.

Бу қара тупрақ эчендә ничәләр Йатурлар ушбу түн күндүз кичәләр Кеме солтан кеме қол кеме әмир Кеме хуҗа кеме бай кими фақир Кеме уџлан кеме шәйх кеме фәта Йите мең мотрибчиләрим бар иди Мең̧е чәң мең̧е қубызчылар иди Мең̧е найчиләр иди мең̧е бырғу Мең̧е табл орар ирди мең̧е орғу Мең̧е чалғу чалар ирди мең̧е дәф Мең̧е чимбал орар ирди мең̧е кәф Мәҗлисимдә бу қамуџ эшләр имди.
Х. Кятиб. «Җөмҗөмә солтан», 1370 ел.

16 нчы бирем. а) йитте, йигел, йимеш, йиң сүзләренең генетик чыганагы берме? Шуны аңлатып бирегез. б) Йимеш сүзенә этимологик анализ ясагыз.

- Заһид йитте бичин бағына тәмам.
- Төрлүк йимеш килтереп, йигел- тиде.
- Кәрәгенчә сән йимеш алғыл тиде.
- Йимеш илә, йиң, итәген тултырып.

Мөхәммәдьяр. «Төхфәи мәрдан», 1539 ел.

17 нче бирем. XVI йөздә иҗат ителгән әсәрләрдә әдәби тел белән халык теле арасындагы мөнәсәбәтне аңлатыгыз. Хәзерге телдә диалекталь булган сүзләрне күрсәтегез.

Өй мөйешендә иске мамыкны алып Ул кичә игәреп киләпкә сарып
Таң йаруғач иргә бирде сатмаға Көндәге ғадәтчә тәғам алып кайтмаға.
Мөхәммәдьяр. «Төхфәи мәрдан», 1539 ел.

18 нче бирем. Түбәндәге сорауларга җавап бирегез: 1) Тары, тун сүзләренең борынгы телдә нинди мәгънәләре булган? 2) Телнең тарихи үсешендә фонетик тәңгәллекләр мәгънә үзгәрешенә китерәме? Шуны бавыр//бәгырь, аяк//азак, буй//бот сүзләре мисалында аңлатыгыз.

19 нчы бирем. Текстка стилистик анализ ясагыз: 1) Бу өзекләр нинди стильне чагылдыра һәм аларда нинди сурәтләү чаралары бар?
2) Борынгы грамматик формаларны аңлатып бирегез.

1. Ғадел берлә бу җиһан мәғмур ирер Ғадел берлә уш җиһан пор нур ирер Ғадел булыр барча эш башы белең Ғадел берлә даимә бәс эш кылың

2. Сабыр бабын қылайым сезгә бәйән Сабыр итеңез барча эшдә һәр заман Сабыр қылмақ иргә ирер хуш һөнәр Сабыр қылған кешене тәңре үгәр

3. Ғафу бөстанының и таза гөле Қаршыңызда сайрап уш тел былбылы Ғафу бабын имдиқ хуш раушан итәр Сүзләрене күңелләр гөлшан итәр

4. Йөзе балқырди бу қызның нур тик Оҗмахдин йаңы чыққан хур тик
Мөхәммәдьяр. «Нуры содур», 1542 ел.

20 нче бирем. Казан ханлыгы чорында рәсми-канцелярия, дипломатия стилен чагылдырган эш кәгазьләрен күрсәтегез.
«Ибраһим хан йарлыгы»нда (XVI йөз) иске татар теле сүзләрен һәм формаларын табыгыз, аларга аңлатма бирегез.

Ибраһим ханымыз Сөйүрғал сүзүм Ходай ризаси үчүн Мөхәммәд рәсулуллаһ шәфәғати үчүн бу үксүз уғлу ул тул хатунниң азат тархан булсун тидүк. Бу азад йибәргән кем ирсәләрниң ати башлығ Гөлбостан хатун уғли Мөхәммәд Ғазиз хан Наиб шаһ нәсәбе Җанәкә солтан Бу атлы кем ирсәләрни азад йибәрүлди Тәқи Хуш килди атлиғ чурасин бергә булсун тидүк Вә тәқи Мөхәммәд Ғазизның ийәси сөйүрғаб биргән бу ики тамға урманин сөйүрғаб ил ағалари берлә ирақта сөйүрғадуқ Булардин билгүсиз кем-кем ирсә урманларүнә йүрүмасунлар игин саба сурса хәзре анбар алалмасунлар булырга күч берлә қунақ қундурмасуннар тархан илчи улағ алмақ тутмасунлар.

21 нче бирем. Текстка тарихи-грамматик анализ ясагыз, хәзер искергән формаларны татар телендәге диалектлар белән чагыштырыгыз һәм аларга аңлатма бирегез.
Ул қолы учсуз сатыйн алдачи сән Аны сатыб үкүш ниғмәт булдачи сән Мөлек вә дәүләт ийәси булдачи сән
Ул сәбәбдән үкүш рахәт күрнүр имди… Малик әйдер бу қолмыдыр бәйан әйләң Нә мәгнәдин сатарсыз аны сөйләң

Нә сәч қылды нишә качди дугры сөләң Гаклы күрке сездән даџы артық имди Анлар әйдер һич гөм ансыз байық қолдыр Қолымызның үч дөрлү ғәйбе вардыр Уғрыдыр йаланчидыр қачқучидыр
Бу үч дөрлү ғәйбе берлә алғыл имди
«Кыйсса-и Йосыф» (Казан,1893, 22, 27 б.).

22 нче бирем. М.Мөхәммәдьяр әсәрләренең тел-стиль үзенчәлекләре белән танышыгыз. Текстны хәзерге әдәби телгә күчерегез һәм язып алыгыз, тарихи яктан лексик һәм грамматик анализ ясагыз.
Бар иде бер падишаһ намедар
Дәүләт вә икбаль вә сәғадәт бәхтийар Ирерди һәм тиң һәмдәм Искәндәри Мәшриқъ мәғърибне тотмыш ләшкәри Үзе билә хезмәтендә ничәләр
Йөрер ирде шәһәр эчендә кичәләр Йахшы йаман кемләр имеш аңлайу Йөрер ирде үзе өйләр тыңлайу
Кучә эчендә йөрер ирде йаруқлықны күреп Ни йаруқ тип аңа барды торып
Күрдисә бер ғаҗип туйдыр олуғ Өйнең эче хатынлар ирде тулуғ Ике кемсәултырыр монлар ара Илкигә алмыш анлар қаләм қара Шаһ күрер һич кеше күрмәс моны
Бу ғаҗип сердер һич кеше белмәс моны
Мөхәммәдьяр. «Төхфәи мәрдан», 1539 ел.

23 нче бирем. Г.Кандалый шигырьләренең тел-стиль үзенчәлекләрен билгеләгез. Әдипнең әсәрләрен төрле чорларда (Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгында) иҗат итүче шагыйрьләрнең әсәрләре белән чагыштырып, тел үзенчәлекләрендә аерманы ачыклагыз.

24 нче бирем. Г.Тукай шигырьләренең тел-стиль үзенчәлекләрен тикшерегез.

25 нче бирем. Ф.Әмирхан әсәрләренең тел-стиль үзенчәлекләрен анализлагыз.

Реферат һәм махсус сораулар буенча якынча темалар

1. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасы һәм аның тел-стиль үзенчәлекләре
2. Харәзминең “Мәхәббәтнамә” әсәре һәм аның тел-стиль үзенчәлекләре.
3. Котбның “Хөсрәү вә Ширин” поэмасы һәм аның тел-стиль үзенчәлекләре.
4. С. Сараиның “Гөлстан бит-төрки” әсәренең теле.
5. Мөхәммәдъяр әсәрләренең тел-стиль үзенчәлекләре.
6. Татар милли әдәби телендә вокализм, андагы тарихи үзгәрешләр.
7. Татар милли әдәби телендә консонантизм, андагы үзгәрешләр.
8. XIX гасырларда поэзия теле (Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки, Г. Чокрый, Акмулла, Г. Кандалый, Баһави һ.б.).
9. XIX гасырда проза теле (К. Насыйри, М. Акъегет, З. Бигиев һ.б.).
10. XIX гасырда драматургия стиле формалашу.
11. Мирза Казыймбәк грамматикасында татар теле мәсьәләләре.
12. Татар әдәби телен һәм фәнни стильне үстерүдә Ш. Мәрҗанинең тоткан урыны.
13. К. Насыйриның татар тел белемен һәм әдәби телне үстерүдәге эшчәнлеге.
14. Татар әдәби телен үстерүдә Г. Тукайның роле.
15. Ф. Әмирханның татар әдәби телен үстерүдә тоткан урыны.

16. Г. Исхакыйның татар милли әдәби телен үстерүдәге эшчәнлеге.
17. Г. Ибраһимовның татар тел белемен һәм әдәби телне үстерүдәге роле.
18. Г. Коләхметовның әдәби телне үстерү өлкәсендәге эшчәнлеге.
19. Ш. Бабичның шигъри теле.
20. Татар тел белеменең 20-30 нчы елларда үсеше һәм уку йортларында телне гамәлгә кую мәсьәләләре.
21. Әдәби телнеңстилистик системасы үсешендә төп тенденцияләр.

Подготовка и защита реферата

Рекомендации к выполнению реферата.

Реферат должен иметь следующую структуру: титульный лист, содержание, основная часть, заключение, список используемой литературы, при необходимости приложения.

Титульный лист. Титульный лист реферата должен содержать название факультета, кафедры, направления подготовки и (или) программа подготовки студента, название темы, фамилию, имя, отчество автора, фамилию, инициалы научного руководителя, год выполнения.

Содержание. В нем последовательно излагаются названия пунктов реферата, указываются страницы, с которых начинается каждый пункт.

Введение. Объем от 1 до 1,5 страниц. Во введении формулируется суть исследуемой проблемы, обосновывается выбор темы, ее актуальность, указываются цель (цель исследования – то, что в конечном итоге необходимо выяснить, изучая тему (примерные формулировки: выявить особенности (сущность)…провести сравнительный анализ и определить…; определить основные (характерные) черты …; обозначить (выявить) специфику явления и т.п.) и задачи (задачи исследования – это средства достижения цели. Например, - подобрать и изучить литературу по теме; провести аналитический обзор литературы; проанализировать

…; осветить …; исследовать …; рассмотреть процесс (явление) и т.п.) работы над рефератом, дается характеристика используемой литературы (например, «При изучении данной темы мной была изучена литература

…, в которой рассмотрены (представлены) … В наибольшей степени проблема (вопрос) освещены в … (книге, статье, монографии и т.п.)»).

Основная часть состоит из глав. Каждая глава начинается с новой страницы и, доказательно рассматривая отдельную проблему или одну из ее сторон, является логическим продолжением предыдущей главы; в основной части могут быть представлены таблицы, графики, схемы.

Заключение. В нем подводятся итоги работы над темой, делаются выводы в соответствии с целями, поставленными во введении, предлагаются рекомендации по изучению данной проблемы.

Список литературы выполняется в соответствии со стандартами написания библиографических данных в алфавитном порядке.

По усмотрению преподавателя рефераты могут быть представлены на семинарах, научно-практических конференциях.

Критерии оценивания:

- изложение постановки проблемы, содержания исследования и его основных результатов;
- демонстрируется знакомство автора с основной литературой вопроса;
- умение выделить проблему и определить методы ее решения;
- умение последовательно изложить суть рассматриваемых вопросов;
- владение соответствующим понятийным и терминологическим аппаратом;
- приемлемый уровень языковой грамотности, включая владение функциональным стилем изложения.

Оформление реферата:
1. Реферат оформляется объемом 5-10 страниц на листах формата А 4. Печатный текст должен соответствовать следующим требованиям:
2. Шрифт Times New Roman, кегль № 14, полуторный интервал, отступ 1,25 (абзац).
3. Поля: левое – 3 см, правое – 1,5 см, верхнее и нижнее по 2 см.
4. Номера присваиваются всем страницам, начиная с титульного листа, нумерация страниц проставляется со второй страницы по центру на нижнем поле.
5. Все заголовки по центру.
6. Заголовки ГЛАВ, СОДЕРЖАНИЕ, ВВЕДЕНИЕ, ЗАКЛЮЧЕНИЕ, СПИСОК ЛИТЕРАТУРЫ заглавными буквами. Точку в конце названий не ставьте.
7. Знаки препинания необходимо ставить после ссылок. Пример: [1; 56], [1; 15].
8. Рисунки подписываются внизу по центру, 12 шрифтом

## 6. Учебно-методическое и информационное обеспечение дисциплины (модуля)

### 6.1. Перечень учебной литературы, необходимой для освоения дисциплины (модуля)

**Основная учебная литература:**

1. Хисамова Ф.М. Татар теленең тарихи грамматикасы: Фонетика. Морфология / Ф.М. Хисамова. – Казан: Татар. кит. нәшр., – 2017. – 183 б.
2. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе (Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 295 б.
3. История родного (татарского) языка [Электронный ресурс] : Учебно-методическое пособие по направлению 44.03.05. Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки), «Родной (татарский) язык и литература, Русский язык», «Родной (татарский) язык и литература, Иностранный язык», «Родной (татарский) язык и литература, Начальное образование» / ; СФ БашГУ; автор-составитель Н. А. Мукимова, ответственный редактор И. С. Мансуров .— Стерлитамак : Изд-во СФ БашГУ, 2021 .— 58 с. — (на татарском языке) .— Электрон. версия печ. публикации .— Доступ возможен через Электронную библиотеку БашГУ .— <URL:https://elib.bashedu.ru/dl/local/MukimovaNA_Istor_rodnogo_tatars_yaz_ump_2021.pdf>

**Дополнительная учебная литература:**

1. Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр - XX йөз башы) / И.Б. Бәширова, Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадыйрова; фәнни ред. Ф.М. Хисамова. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 1 т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. – 696 б.
2. Татар лексикологиясе: өч томда / проект. җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – Т. II. – 392 б.
3. Җәләй Л. Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар). – Казан: Фикер, 2000. – 288 б.

### 6.2. Перечень электронных библиотечных систем, современных профессиональных баз данных и информационных справочных систем

| № п/п | Наименование документа с указанием реквизитов |
|---|---|
| 1 | Договор на доступ к ЭБС ZNANIUM.COM между БашГУ в лице директора СФ БашГУ и ООО «Знаниум»№ 3/22-эбс от 05.07.2022 |
| 2 | Договор на доступ к ЭБС «ЭБС ЮРАЙТ» (полная коллекция) между БашГУ в лице директора СФ БашГУ и ООО «Электронное издательство ЮРАЙТ» № 1/22-эбс от 04.03.2022 |

| | |
|---|---|
| 3 | Договор на доступ к ЭБС «Университетская библиотека онлайн» между БашГУ и «Нексмедиа» № 223-950 от 05.09.2022 |
| 4 | Договор на доступ к ЭБС «Лань» между БашГУ и издательством «Лань» № 223-948 от 05.09.2022 |
| 5 | Договор на доступ к ЭБС «Лань» между БашГУ и издательством «Лань» № 223-949 от 05.09.2022 |
| 6 | Соглашение о сотрудничестве между БашГу и издательством «Лань» № 5 от 05.09.2022 |
| 7 | ЭБС «ЭБ БашГУ», бессрочный договор между БашГУ и ООО «Открытые библиотечные системы» № 095 от 01.09.2014 г. |
| 8 | Договор на БД диссертаций между БашГУ и РГБ № 223-796 от 27.07.2022 |
| 9 | Договор о подключении к НЭБ и о предоставлении доступа к объектам НЭБ между БашГУ в лице директора СФ БашГУ с ФГБУ «РГБ» № 101/НЭБ/1438-П от 11.06.2019 |
| 10 | Договор на доступ к ЭБС «ЭБС ЮРАЙТ» (полная коллекция) между УУНиТ в лице директора СФ УУНиТ и ООО «Электронное издательство ЮРАЙТ» № 1/23-эбс от 03.03.2023 |

**Перечень ресурсов информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» (далее - сеть «Интернет»)**

| № п/п | Адрес (URL) | Описание страницы |
|---|---|---|
| 1 | https://turkicmap.antat.ru/ | Интерактивная карта тюркских языков Поволжья |

### 6.3. Перечень лицензионного и свободно распространяемого программного обеспечения, в том числе отечественного производства

| Наименование программного обеспечения |
|---|
| Office Standart 2010 RUS OLP NL Acdmc - 200 /Лицензионный договор №04297 от 9.04.2012 |
| Windows XP - Лицензионное соглашение MSDN. Государственный контракт №9 от 18.03.2008 г. ЗАО «СофтЛайн» |
| Office Standart 2007 Russian OpenLicensePack NoLevel Acdmc - 200 / ООО «Общество информационных технологий». Государственный контракт №13 от 06.05.2009 |

## 7. Материально-техническая база, необходимая для осуществления образовательного процесса по дисциплине (модулю)

| Тип учебной аудитории | Оснащенность учебной аудитории |
|---|---|
| Учебная аудитория для проведения занятий лекционного типа. Учебная аудитория для проведения занятий семинарского типа. Учебная аудитория групповых индивидуальных консультаций. Учебная аудитория текущего контроля и промежуточной аттестации | Учебная мебель, доска, мультимедиа-проектор, экран настенный, учебно-наглядные пособия |
| Компьютерный кабинет. Учебная аудитория для курсового проектирования. Учебная аудитория для проведения занятий семинарского типа. Учебная аудитория групповых индивидуальных консультаций. Учебная аудитория текущего контроля и промежуточной аттестации | Учебная мебель, доска, персональный компьютер с доступом к сети Интернет |
| Помещение для хранения и профилактического | Демонстрационное |

| | |
|---|---|
| обслуживания учебного оборудования | оборудование |
| Учебная аудитория для проведения занятий семинарского типа. Учебная аудитория групповых индивидуальных консультаций. Учебная аудитория текущего контроля и промежуточной аттестации. | учебная мебель, доска |
| Читальный зал: помещение для самостоятельной работы | Учебная мебель, учебно-наглядные пособия, компьютеры с доступом к сети «Интернет» и ЭИОС Филиала |